Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Гимназия №184 им.М.И.Махмутова»
Советского района г.Казань

Принято на заседании методического
(педагогического) совета
Протокол №1
от 28 августа 2023 года

Утверждено
Директор МБОУ «Гимназия
№ 184 им.М.И.Махмутова»
Приказ № 185 от 28.08.2023
________ Э.М.Салахова

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА ДОПОЛНИТЕЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ**

# «Сэлэт»

**Направленность:** *социально-гуманитарное*

**Возраст учащихся:** *11-15*

**Срок реализации:** *1 год*

**Автор составитель:** Ахметова Г.А.

*Педагог дополнительного образования*

Казань, 2023

**Эчтәлек**

I. Аңлатма язуы...........................................................3-6 бит
II. Педагогик оештыру комплексының шартлары..........7 бит
III. Программа эчтәлеге....................................................8 бит
IV. Әдәбият исемлеге.........................................................9 бит
V. Календарь-тематик план ……………......................10-11 бит
VI. Кушымта................................................................12-18 бит

## Аңлатма язуы

Мәктәптә тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегендә бала яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашырга, әйберләрне танып белергә өйрәнә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур. Баланың бөтен тормышы уен. Уенда бала тирә-юнь турында, җәмгыятьнең законнары, кешеләрнең үзара аралашу матурлыгы турында мәгълүмат алып кына калмый, ә бу дөньяда яшәргә, үзенең максатларын төзергә өйрәнә. Ә бу баланың игътибарлы, яхшы хәтерле, дөрес, матур, әйбәт сөйләшә белүен таләп итә. Сәхнәләштерү уеннарында катнашып, балалар образлар, төсләр, авазлар аша тирә-юнь белән танышалар, ә сораулар балаларны уйларга, анализларга, йомгаклау ясарга мәҗбүр итә. Сәхнәләштерү эшчәнлеген алып барганда, һәр бала үзенең кичерешләрен, тойгыларын, теләкләрен, карашларын гадәти сөйләшкәндә генә түгел, ә чит тыңлаучылар алдында күрсәтә алырлык шартлар тудырырга яшьтән үк өйрәтергә кирәк. Еш кына без киң белемле, сәнгатьле сөйләшә белүчеләрне оялчан икәнен, чит кешеләр алдында югалып калуларын күзәтәбез. Бу проблемалар булмасын өчен, башлангыч сыйныфларда театр куюю бик зур булышлык күрсәтә. Сәхнәләштерелгән уеннар балаларны шатландыралар. Спектакльләрдә катнашып, балалар тирә-юнь белән, төсләр, авазлар белән танышалар, ә уйланылып куелган сораулар балаларны анализларга, уйланырга, нәтиҗәләр ясарга өйрәтә. Сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәнү барышында, сизелмичә баланың сүз байлыгы арта, бала чиста, дөрес, аңлаешлы итеп сөйләргә өйрәнә. Сүзлек формалаша - яңа сүзләр белән баетыла.

Сәләтле укучылар өчен оештырылган сәнгать юнәлешендәге бу түгәрәктә укучылар сәхнә серләренә, тылсымлы театр дөньясының матурлыгын ачарга өйрәнәләр. “Күңелле сәхнә” түгәрәге, исеменнән үк күренгәнчә, театр, сәнгать, җыр-бию яратучы укучылар өчен оештырыла.

**Актуальлеге.** Стандартларның яңалыгы-белем һәм тәрбия алуда универсаль гамәлләрнең берсе коммуникатив гамәлләрнең камил формалашуы. Ягъни, баланың үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белүгә әзерләү. Бу таләп – түгәрәкнең актуальлеген раслаучы мөһим дәлил дә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур.

Әдәбият ул – сүз сәнгате. Әмма дәресләр чикле. Өстәмә белем бирү, әдәбиятта яңа исемнәр, аларның иҗаты белән танышу; туган якның әдәбият һәм журналистика әһелләрен, аларның иҗатын киңрәк өйрәнү һәм укучыларның иҗади сәләтләрен ачуны күздә тотып, дәрестән тыш эшләрне “Сәләт” түгәрәгендә алып барырга булдым.

Бу программа инновацион характердагы язуын билгели.

**Практик әһәмияте.** Бу программаны мәктәпләрдә эшләүче театр түгәрәге җитәкчеләре һәм өстәмә белем бирү оешмаларында эшләүче педагоглар үзләренең хезмәтләрендә куллана ала.

**Түгәрәк эшенең укучыларга белем бирүдә үзенә караган аерым таләпләре бар:**

1. Укучыларның түгәрәккә ирекле рәвештә язылуы.
2. Түгәрәк үткәрү өчен метод һәм алымнарны сайлый белү.
3. Укучыларга индивидуаль якын килеп эш итү.
4. Түгәрәк эшләренең кызыклы һәм мавыктыргыч итеп оештырылуы.
5. Түгәрәкнең системалы рәвештә үткәрелүе.

Түгәрәк дөрес һәм системалы оештырылганда гына укучыларга төпле белем һәм

тәрбия бирелә. Дәрес нинди белем һәм тәрбия бирсә, дәрестән тыш эшләр дә шул әһәмияткә ия булып тора.

**Түгәрәкнең максаты.** “Сәләт” түгәрәге оештыруның төп максаты-сәләтле балаларны барлау, аларның иҗади сәләтен үстерүгә шартлар тудыру, татар теле һәм әдәби уку буенча белем бирүнең сыйфатын күтәрү, укучыларда халкыбызның гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре, дине, татар халкының язучылары, шагыйрьләре, драматурглары, артистлары, гомумән, күренекле шәхесләрен өйрәнү аркылы туган телгә һәм халкыбызга мәхәббәт һәм ихтирам хисләре тәрбияләү.

**Түгәрәкнең төп бурычлары.** Әлеге максатка ирешү юлында татар укучыларына әдәби уку фәне буенча түгәрәк үткәрүнең төп бурычлары түбәндәгечә билгеләнә:

1. Укучының татар әдәби телен үзләштерүенә, текстны аңлап, сәнгатьле итеп, төрле темаларга иркен сөйләшүенә ирешү, тел һәм әдәбият буенча иҗади сәләтен үстерү һәм иҗат итәргә омтылыш тудыру.
2. Балаларны мәктәп программасында булмаган, туган ягыбызда яшәп иҗат итүче язучы-шагыйрьләр һәм аларның иҗат үрнәкләре белән таныштыру.
3. Шәһәребез, районыбыз язучыларының иҗатын өйрәнү аша шәһәр, район тарихы, аның күренекле кешеләре, традицияләре белән танышу.
4. Тормышларын әдәбият дөньясына, журналистикага, артистлыкка багышлаган укучыларны киләчәктә мөстәкыйль белем алуга, алган белемнәренә нигезләнеп, укуларын югары уку йортларында уңышлы дәвам итәрлек укучылар хәзерләү.
5. Түгәрәк шулай ук сәхнә серләренә төшенү, кулдан матур киемнәр әзерләү һәм зәвыклы киенү, тамашачылар алдында үз-үзеңне тотарга өйрәнү бурычларын да үз өстенә ала.

**Сәхнәләштерү эшчәнлеге**

- аудиоязмалар тыңлау, курчак театры, мультфильмнар, театраль тамашалар карау һәм алар буенча әңгәмә оештыру;
- уен-драматизацияләр;
- сәнгатьле итеп сөйләү күнегүләре;
- этика буенча аерым күнегүләрне үз өстенә ала.

**Түгәрәккә йөрүче укучылар яше.** Программа 10-15 яшьлек балаларга исәпләнгән. Бу яшьтәге балалар бик кызыксынучан булалар. Ул яшьтәшләрен һәм өлкәннәрне, әти-әнисен күзәтә, аларның психологик сыйфатларын күрә. Шулай ук үз-үзен аңларга, теге яки бу очракта ни өчен үзен шулай хис итүен белергә тырыша. Аларда яңа төрле шатлыклар һәм шикләнүләр барлыкка килә. Хисләр даирәсе киңәя, ул акыл һәм эстетик өлкәләргә дә тарала. Бу яшьтәге балалар театр түгәрәгенә бик теләп һәм кызыксынып йөриләр. Аларның шушы кызыксынуларын тагы да арттырырга кирәк.

**Программаны үзләштерү срогы, күләме.** “Сәләт” түгәрәге программасы бер уку елына төзелгән. Укучылар белән шөгыльләр атнага бер тапкыр 1әр сәгать үткәрелә. Укыту планы буенча 35 сәгатькә исәпләнгән.

**Шөгыль формалары һәм режимы.** Программада һәр атнада бергәләп рольләр өйрәнүләр, төрле конкурслар, очрашулар, сәхнәдә чыгыш ясау каралган. Якташ һәм

балалар язучыларының, күренекле каләм ияләренең әсәрләрен укып өйрәнү, аларга анализ ясау, сәхнәдә иҗади җимешләрен күзәтү укучыларга бер-берсе белән якыннан аралашырга, туган телебезнең матурлыгын тоярга киң мөмкинлекләр ача. Бәйләнешле сөйләм үстерү, сәнгатьлелек, культуралы сөйләм кебек проблемалы мәсьәләләр дә программада урын алган.

**Программаны тормышка ашыруда көтелгән нәтиҗәләр:**
- укучы үзен иркен тотарга өйрәнә, психологик яктан ачыла;
- үзенең мавыгуына туры килгән эш белән шөгыльләнә;
- түгәрәктәге башка укучылар, укытучы белән аралашу вакытында эчке дөньясында ачыла, аралашу әдәбенә өйрәнә;
- укучы фикерләргә, үз фикерен дәлилләргә өйрәнә;
- сөйләм телен камилләштерә ;
- әхлак һәм зәвык тәрбиясе ала;
- шәхес булып тәрбияләнә, үз урынын таба;
- татар теле һәм әдәбияты буенча белемен тирәнәйтә, кызыксыну уята.

**Тикшерү алымнары**: укучыларның шәхси үсеш диагностикасы һәм мониторинг үсеше, чыгыш ясау, бәйгеләр. Түгәрәктә сәхнә серләре белән танышкан укучы дәрестә әсәрләргә анализ ясаганда, үз көченә ышанып, язма эшләр вакытында тел-сурәтләү чараларыннан иркен файдаланып, иҗади фикерләү сәләтенә бай булуын күрсәтә.

**Укучылар белергә тиеш:**
- театр һәм театр сәнгате тарихы турында;
- театр, тамаша залы һәм сәхнә турында;
- театрда үзеңне тоту кагыйдәләре турында;
- актер осталыгының теоретик нигезләре турында;
- сәхнәдә хәрәкәт кагыйдәләре турында;
- текстның эчке мәгънәсен ачыклау.

**Эшли, башкара белергә тиеш:**
- театр сәнгатен башка сәнгать төрләреннән аера;
- сүз басымын дөрес куя белергә;
- сулыш күнегүләрен;
- тавыш һәи дикция күнегүләрен;
- сөйләм ритмын;
- костюмнар һәм декорацияләр әзерләргә;
- грим салырга;
- әкиятләрне сәхнәләштерергә;
- спектакль куярга

**Программа эшчәнлегенә нәтиҗә ясау формалары**. Әти–әниләр, укучылар алдында чыгыш ясау.

**Уку елы ахырында укучылар белергә тиеш:**

1. Театр сәнгате, аның төп узенчәлеген белү.
2. Милли театрыбыз, аның беренче карлыгачларын белү. (Язучы-драматурглары, артист-актерлары, режиссерлары).
3. Актерлык бурычы, образга керү һәм тоемлап сөйләү.
4. Режиссер күрсәтмәләрен аңлый, үти белү.
5. Мәдәниятне аңлый белүче, иҗади талантлы, әхлак сыйфатларына ия кеше булу.
6. Театр сәнгатен башка сәнгать төрләреннән аеру.
7. Сәнгатьле сөйли, образга керү.
8. Иҗади һәм мөстәкыйль эшли, үз киңәшләрен башкаларга да бирә алу.

## Педагогик оештыру комплексының шартлары

**Иҗади коллектив эшчәнлеге технологиясе** әлеге программаны тормышка ашыруда иң кулае. Программа **укучыларның аңлылыгын һәм иҗади активлыгын үстерү принцибына** нигезләнгән. **Укытуны оештыру алымы** – ул төркем белән эшләү. Ә **укыту шөгылен оештыру формасы** – әңгәмә, бәйге, күзәтү, спектакль.

**Педагогик контроль.** Укучылар йөри башлаган беренче көннәрдә үк укучыларның тел байлыгын, сәнгатьле сөйләмен күзәтү максатыннан **алдан тикшерү** үткәрелә**. Агымдагы тикшерү** исә нәни артистларның рольне үзләштерү дәрәҗәсен күзәтү өчен кирәк. Ә **йомгаклау тикшерүе** - артистларның сәхнәдә чыгыш ясаулары. Ул түгәрәк эшчәнлегенә нәтиҗә ясау максатыннан үткәрелә.

**Дидактик материаллар:** китаплар, энциклопедияләр, видеоматериаллар.

**Матди-техник һәм мәгълүмати тәэмин итү:** магнитофон, компьютер, видеоязмалар.

**Методик материаллар.** Программа буенча эш укучылар белән бергәләп оештырыла, укыту методларыннан уен, күрсәтмәле гамәли алымнар, ә стимуллаштыру, мактау кебек тәрбия алымнары да кулланыла.

Түгәрәкнең программасы “Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары”на (Казан, ”Мәгариф” нәшрияты, 2017нче ел) нигезләнеп, театр тарихы, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары, газета-журнал материалларыннан файдаланып төзелде.

## Программа эчтәлеге

**I. Кереш (1 сәгать)**

Кереш дәрес. Укучыларны туплау, түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү.

**II. Казандагы театрлар (5 сәгать)**

Театр тарихы турында белешмә. Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры, К. Тинчурин исемендәге Татар Дәүләт драма һәм комедия театры, Казан дәүләт яшь тамашачылар театры, Татар дәүләт “Әкият”курчак театры турында мәгълүмат бирү.

**III. Туган телем сагында (7 сәгать)**

Укучыларның сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. Сәхнә серләренә өйрәнү. Киенү-бизәнү осталыгы турында сөйләшү, кассетадан чыгышлар карау.

Балаларга ялгыз, парлы, күмәк бию элементларын өйрәтү. Бәйрәмнәрдә чыгыш ясау.

**IV. Милли хәзинә (8 сәгать)**

Татар халык иҗаты белән танышуны дәвам итү. Татар халык иҗатының үзенчәлекләрен билгеләү.

Татар халкының сәхнә уеннары, такмак, такмаза, тел шомарткычлар турында мәгълүмат бирү. Мәкаль, әйтемнәр һәм табышмаклар буенча ярышлар үткәрү, әкиятләр сәхнәләштерү. Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү, сәхнәдә кую.

Җырлы уеннар. Бәйрәмнәрдә, атналыкларда чыгыш ясау.

**V. Туган ягым – яшел бишек. (6 сәгать)**

Бүгенге көндә экологик проблема һәм аның әһәмияте. Табигатьне саклауга өлеш кертү: тирә-юньнең чисталыгын саклау, агачлар утырту, чишмәләрне чистарту, кошларга, җәнлекләргә карата мәрхәмәтле булырга кирәклеген төшендерү.

Экологик темага кичә үткәрү.

**Р.Вәлиеваның ”Кыңгырау чәчәк”** әсәрен өйрәнү, чыгыш ясау.

**VI. “Театр яктылыкка илтә”(6 сәгать)**

Театр, туган тел атналыгы оештыру (атналык программасы аерым төзелә). Атналыкта катнашу өчен Рафис Корбанның **“Керпе малае дуслар эзли”** әсәрен сәхнәләштерү.

Балалар өчен язылган җырлар тыңлау. Иң матур җырларны өйрәнү, сәхнәдә башкарырга (аерым, күмәк) әзерләнү. Җырга карата киемнәр сайлау.

Кызлар-малайлар белән парлы вальс өйрәнүне дәвам итү.

**VII. Йомгаклау (2 сәгать)** Әти–әниләр, башлангыч сыйныфлары алдында чыгыш ясау.

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**


1. Әхәт Гаффар: балалар өчен әкиятләр, хикәяләр, пьесалар. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2016.
2. Балалар фольклоры. Казан:/ Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2009.
3. Бәби: балалар өчен пьесалар/Илгиз Зәйниев. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2018.
4. Вагыйзов С. Г. Кызыклы грамматика. Татар теленнән дидактик уеннар һәм мавыктыргыч күнегүләр. Тулыландырылган икенче басмасы. Казан. Тат.кит.нәшр., 1980.
5. Гөлбакча. Балалар бакчалары өчен хрестоматия. Төзүчеләре: Ф.Ю. Юсупов, З.Ф. Камалова, Р.А.Борһанова. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1990.
6. Исмәгыйлева С.Г. Татар теленнән класстан тыш эшләр. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1981.
7. Зиннурова Ф.М. Бала сөйләмендәге кимчелекләрне төзәтү. – Казан: Мәгариф, 2005.
8. Кабыргалы-камчылы: Татар халык уеннары. - Казан: Мәгариф, 2002.
9. Малай-шалайлар: балалар өчен шигырьләр/Роберт Миңнуллин. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2019.
10. Мәктәп сәхнәсе өчен пьесалар [төз.Р.Сәлах]. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2017.
11. Нәкый Исәнбәт. Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен. Казан: Татарстан китап нәшрияты,1984.
12. Нуриев Г.Р. С. Сәнгатьле уку. Методик ярдәмлек. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2000.
13. Рәүфә Уразман. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1992.
14. Рәшит Ягъфәров. Кәҗә-мәкәрҗә. – Казан ”Мәгариф”, 1994.
15. Сүз эчендә хикмәт бар: мәкальләр, әйтемнәр, канатлы сүзләр/ төз. Т.Р. Шакирова. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2010.
16. Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия. Төзүчеләре: Л.И. Минһаҗева, И.Х. Мияссарова. - Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2003.
17. Татар драматургиясе (1980 - 2000 еллар): Сайланма пьесалар. - Казан: “Хәтер” нәшрияты, 2003.
18. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда/ Нәкый Исәнбәт. - 2 нче басма. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2010.
19. Татар балалар әдәбияты. Шигырьләр һәм пьесалар. Төзүчесе: С.Г. Сәмитова.- Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты (ТаРИХ), 2003.

19\. Хафизова Р.С. Карурманда ниләр булмас: Әкиятләр, әкият-пьесалар. Кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары өчен. - Казан: Мәгариф, 1999.

20\. Шәрифуллина Э.М. Җырлы бәйрәм. Мәктәпләрдә әдәби-музыкаль кичәләр үткәрү өчен кулланма. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшрияты, 2011.

21\. Ягъфәрова Р.Х. Уку әсбабы. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2017.

Календарь-тематик план
(35 сәгать)

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| I. | **Кереш дәрес.** | 1 |
| II. | **Казандагы театрлар.** | 5 |
| | Театр тарихы турында белешмә. | 1 |
| | Татар дәүләт “Әкият” курчак театры. | 1 |
| | Казан дәүләт яшь тамашачылар театры. | 1 |
| | Г. Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры һәм К. Тинчурин исемендәге Татар Дәүләт драма һәм комедия театры. | 1 |
| | М.Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры. | 1 |
| III. | **Туган телем сагында.** | 7 |
| | Тел осталыгына ничек ирешергә? Сәнгатьле сөйләм күнекмәләре. | 1 |
| | Сөйләм культурасы. Әдәби тел нормалары. | 1 |
| | Сәхнә серләренә өйрәнү. Киенү-бизәнү осталыгы. | 1 |
| | Татар халкының бию элементлары (кызлар өчен). | 1 |
| | Татар халкының бию элементлары (малайлар  өчен). | 1 |
| | Күмәк бию элементлары. | 1 |
| | Җырлы – биюле уеннар. | 1 |
| IV. | **Милли хәзинә** | 8 |
| | Татар халык иҗаты белән танышу. Татар халык иҗатының үзенчәлекләрен билгеләү. | 1 |
| | Такмаза, тел шомарткычлар. | 1 |
| | Тизәйткечләр, такмаклар. | 1 |
| | Табышмаклар, мәкальләр һәм әйтемнәр. | 1 |
| | “Кәрия–Зәкәрия”, “Күрсәт әле, үскәнем” җырлы-уеннар. | 1 |
| | “Ак калач” җырлы- уен. | 1 |
| | Мәзәкләр сәхнәләштерү. | 1 |
| | Әкиятләр сәхнәләштерү. | 1 |
| V. | **Туган ягым – яшел бишек.** | 6 |
| | Бүгенге көндә экологик проблема һәм аның әһәмияте. | 1 |
| | Р. Вәлиеваның ”Кыңгырау чәчәк” әсәрен уку, фикер алышу | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Кыңгырау чәчәк белән Куян образлары | 1 |
| | Куян белән малай образы | 1 |
| | Кыңгырау чәчәкнең җырын өйрәнү. | 1 |
| | Р.Вәлиеваның ”Кыңгырау чәчәк” әсәрен тулысынча кабатлау. | 1 |
| VI . | **“Театр яктылыкка илтә”** | 6 |
| | Р. Корбанның “Керпе малае дуслар эзли” әсәре белән танышу, рольләргә бүлү. | 1 |
| | Керпеләр диалогын өйрәнү | 1 |
| | Ата, ана һәм керпе малаеның диалогы (хәрәкәтләр). | 1 |
| | Керпе малае һәм Төлкенең җырын өйрәнү. | 1 |
| | Декорация һәм киемнәр әзерләү. | 1 |
| | Р. Корбанның “Керпе малае дуслар эзли” пьесасын тулысынча кабатлау. | 1 |
| **VII** | **Йомгаклау** | 2 |
| | Мәктәпләрнең башлангыч сыйныфлары алдында чыгыш ясау. | 1 |
| | Атналыкларда катнашу. “И туган тел, и матур тел” (интеллектуаль викторина) | 1 |
| | **Барлыгы** | 35 |